Республика Татарстан
Совет Петровско-Заводского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06 август 2019 ел Петровский Завод авылы №12

Петровский Завод авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезлэмэне раслау хакында"гы 19нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон» , Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендэ, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль Петровский Завод авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Петровский Завод авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезлэмэне раслау хакында" гы 19нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешлэр кертергэ:
1) 4 бүлекнен 4.1.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.Гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашында хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә алдагы этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO) TATARSTAN.RU («Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль район
Петровский Завод авыл җирлеге
Советы рәисе А.Б.Хөснетдинов